**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**
**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының "Кече Бөгелмә авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге составына керүче Алга поселогы торак пункты**

**2024 елның 15 ноябре** **№ 2**
**13.00**
**Алга Бистәсе,**
**1 нче Алга урамы**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Кече Бөгелмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Алга поселогы торак пунктында гражданнар җыены нигезендә

карар кылды:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Кече Бөгелмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Алга поселогы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, тыл хезмәтчәннәреннән, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә.

2.Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:
- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (Алга бистәсендә Бөек Ватан сугышы вакытында тыл хезмәтчәннәренә куелган һәйкәл янындагы территорияне төзекләндерү максатларында койма кору, тротуар плитәсе салу өчен төзелеш материаллары сатып алу һәм башка эшләр).

**Гражданнар җыенында рәислек итүче**
**Бөгелмә муниципаль районының**
**"Кече Бөгелмә авыл җирлеге"**
**муниципаль берәмлеге Башлыгы__________** **В. Б. Григорьев**